ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

07.04.2021 Иннополис шәһәре №65

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябреннән 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009нчы елның 28нче декабреннән 381-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016нчы елның 13нче августындагы 553нче номерлы карары белән Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре
Башкарма комитетының
2021нче елның 7нче
апреленнән 65нче номерлы
карарына

Кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы.

| № | Реестр номеры | Факттагы адресы | Факт буенча профиле | Мәйданы, кв. м |
|---|---|---|---|---|
| 1 | А-1 | Квант бульвары, 3нче йорт янында | Азык-төлек булмаган | 100дән артык түгел |
| 2 | А-2 | Парковая урамы, 1нче йорт янында | Азык-төлек | 5тән артык түгел |
| 3 | А-3 | Спорт урамы, 102нче йорт янында (парк зонасы) | Азык-төлек | 5тән артык түгел |
| 4 | А-4 | Квант бульвары, 2нче йорт янында (парк зонасы) | Азык-төлек | 5тән артык түгел |